ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2019 ел Баулы шәһәре № 313

2020 елга Баулы муниципаль районы балаларына туристлык - туган якны өйрәнү, экология - биология, хәрби-патриотик, социаль - педагогик, социаль - икътисадый, табигый - фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирүче белем бирү оешмаларында һәм балаларга күпьюнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законының 99нчы статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законныж 15 статьясы 1нче өлеше 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасы балаларына туристик-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик социаль - икътисадый, табигый - фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге остәмә белем бирүче белем бирү оешмаларында һәм балаларга күпьюнәлешле өстәмә белем бирү оешмалары нормативларын исәпләү нигезләмәсен раслау турында» 939 номерлы карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2020 елга расларга:

кушымтадагы Баулы муниципаль районы балаларына туристлык - туган якны өйрәнү, экология - биология, хәрби-патриотик, социаль - педагогик,

социаль - икътисадый, табигый - фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирүче белем бирү оешмаларында һәм балаларга күпьюнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында норматив чыгымнарны расларга;

балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан коненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

И.И. Хөснуллина